Ботен галəмнəрне юктан бар Итvчегə, мəхлvкəтне барлыкка китереп тəрбия Итvчегə, Əдəм балаларына ризык, нигъмəт Бирvчегə, кыямəт коненен Хужасына - Аллаһы Раббыбызга хəмед вə сəнə, олуглау вə мактауларыбыз булса иде!
Ботен галəмнəргə Аллаһынын рəхмəте булып ирешкəн, ике доньянын бəхетенə ирешvгə сəбəпче булган соекле пəйгамбəре Мохəммəд Мостафа салаллаһу галəйһи вəссəламгə барчабызнын да ихлас калеблəребездəн кайнап чыккан салават шəрифебез булса иде!
Мохтəрəм дин кардəшлəр, газиз ватандашлар!
Əссəламv галəйкvм вə рəхмəтуллаһи вə бəрəкəтvһ!
Россия Федерациясе моселманнарынын Үзəк диния нəзарəте исеменнəн, шəхсəн vз тарафымнан сезне килəсе мобарəк Гарəфə коне һəм Ид-əл-Əдха Корбан бəйрəме унаеннан ихлас кvнелемнəн тəбрик итəм!
Шушы мобарəк коннəрне хажиларыбызнын Гарəфəт тавында кылган ихлас догаларын, Мина vзəнендə кылган гамəллəрен, суйган корбаннарын, Гает конне Кəгъбəтуллаһны саубуллашу кылган арада изге догаларын Аллаһы Тəгалə кабул əйлəсен!
Безлəрнен да шушы мобарəк- Гарəфə, Ид-əл-Əдха Корбан бəйрəм коннəрендə кылган ихлас догаларыбызны, тəшрикъ коннəрендə суйган корбаннарыбызны кабул əйлəсен!
Барча дин кардəшлəребезгə, гаилə əһеллəребезгə, туган-тумачаларыбызга Аллаһ исəнлек-саулык бирсен!
Ил-коннəребез тыныч һəм имин булсын, vзебезне, дəvлəтебезне Аллаһ бəла-казалардан, кайгы-хəсрəтлəрдəн Үзе сакласын, туасы таннарны, килəсе коннəрне Аллаһ аяз кылып, бергə-бергəлəшеп каршы алырга насыйп итсен! Əмин!

**Рафаэль-хазрат МАНЮРОВ,** *олы ихтирам, хәер-дога, сәламнәр белән сезгә,*

*Мордовия Республикасында Россия Федерациясе мөселманнарынын Үзәк диния нәзарәте тулы хокуклы вәкиле*